Сентябрь • 2020 ел • № 3 (33)
minem-gimnaziyam.jimdo.com

# Минем гимназиям

2 нче ГИМНАЗИЯ

«М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе газетасы





## Саумы, гимназиям!

Менә ул көн килеп тә җитте. Чаллы шәһәренең Мулланур Вахитов исемендәге гимназия балалары өчен бу көн аеруча да көтелгән иде. Яңартылган мәктәпләре каршы алды аларны.

Тантаналы линейкага Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Чаллы шәһәре хакиме Наил Мәһдиев һәм бик күп мәртәбәле кунаклар килгән иде. Гимназия милли мәгариф үзәге булачак. Фәннәрне татар телендә үзләштереп, татар, рус, инглиз телләрендә иркен аралашучы шәхесләр тәрбияләү кебек зур максат куела биредә. Капиталь төзекләндерелгән, якты, заманча мәктәпкә быел 92 бала беренче сыйныфка керә. «Телебезне, гореф-гадәтләребезне сакларга теләгән ата-аналар килгән монда. Әлегә республикада алты полилингваль мәктәп бар, киләчәктә аларның санын арттырырга исәплибез», – дип белдерде Фәрит Мөхәммәтшин.

Интерьер традицион татар орнаменты стилендә бизәлгән. Беренче катта Татарстанның танылган шәхесләре турындагы стенд урнаштырылган. Диварларда әкият геройлары – Су анасы, Шүрәлеләр, акыллы гыйбарәләр...

Һәммә җиһаз да өр-яңа! Һәр сыйныфта – интерактив такта.

Сыйныф бүлмәләрендә – үтә күренмәле витраж ишекләр. Ике спорт залы. Берсендә гимнастика белән, икенчесендә көрәш белән шөгыльләнәчәкләр... Үзгәрешләр күп! Алар бар да ныклы белем һәм тәрбия алу өчен эшләнелгән. Республика бюджетыннан 176 миллион сум бүлеп бирелгән, «Медик», IMS компанияләре хезмәт куйган. Бары тик тырышып укыйсы, мөмкинлекләрдән файдаланып киләчәккә атлыйсы бар.

Уңышлар сезгә, укучылар!

(«Көмеш кыңгырау» газетасыннан)








**Быел гимназия бинасы гына үзгәреп калмады, укучылар формасына тагыла торган шевронның логотибы да үзгәрде.**

Гимназия логотибының нигезендә октаган (сигез тигез почмаклы фигура) ята. График сурәтләү ягыннан караганда, сигезпочмак – квадрат белән әйләнә арасында арадаш фигура, ә рухи яктан караганда, ул дөньялык тормыш белән мәңгелекнең уртаклыгын гәүдәләндерә. Квадратның тотрыклыгы һәм әйләнәнең бөтенлеге. Октаганны кисеп узучы сызыклар укучыларның тормыш үрләрен яулауда үсеш юлларын һәм мөмкинлекләрен аңлата. Сигезпочмакның әйләнә белән кисешкән сызыклары урынында барлыкка килгән ярымкублар шомартылган җәүһәрнең чикләрен хасил итә, ул кыйммәтле таш җиңү һәм бәхәссез өстенлек символы булып санала. (Данис ДӘМИНОВ, Алия НУРИСЛАМОВА тәрҗемәсе).

P.S. Гимназиянең тәнәфескә чакыручы кыңгырау чыңы джинглга («джингл» инглиз теленнән тәрҗемә иткәндә, «радио һәм телеэфир өчен махсус әзерләнгән музыкаль яки вокаль продакшн-элемент, тәмамланган музыкаль фраза мәгънәсендә») алышынды. Бу джингл Факил Сафин язган «Икенче гимназия» җырының музыкасын махсус эшкәртеп ясалды, авторы – сәләтле музыкант, «Ике яр» группасы җитәкчесе, кайчандыр икенче гимназияне тәмамлаган укучыбыз – Марат Минсабир улы Вәлиев. Афәрин, Марат абый!

# Татарча диктант Яз.








Быел «Татарча яз!» бөтендөнья акциядә 379 мең кеше катнашты. Бу акциянең максаты: татар телендә хатасыз язарга өйрәтү, татар әдәби телен кулланучыларның даирәсен арттыру. Һәр теләгән кешегә диктантны онлайн-режимда «ТНВ-Татарстан» һәм «ТНВ-Планета» каналлары оештырган форматта яисә махсус яздыру мәйданына килеп язарга, үзенең татар телен белү дәрәҗәсен тикшереп карарга мөмкин иде.

Быел да безнең гимназия акция уздыру пункты булды. Ул көнне гимназиядә чын бәйрәм рухы сизелеп торды. Ремонтның буяу исләре чак кына кибеп өлгергән гимназия матурлыгы белән кунакларны сокландырды. Мәҗлесләр залында укучылар күрсәткән «Ике фикер» тамашасы аларның кәефләрен тагын да күтәрә төште.

Татарча диктант язар өчен килгән ата-аналарны күреп, без бик сөендек. Алар белән беррәттән Яр Чаллы Башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары Хәлимов Рамил Мәрван улы, шәһәрнең Мәгариф һәм Яшьләр Идарәсе башлыгы Хуҗин Нияз Рөстәм улы кебек мәртәбәле кунаклар да, парта артына утырып, үз белемнәрен тикшерделәр. Диктант яздыру эше Яр Чаллы Татар дәүләт театры актрисасы, Татарстанның атказанган артисты, Дамир Сираҗиев исемендәге премия лауреаты Энҗе Фрунзе Кызы Шиһаповага, Яр Чаллы шәһәре «Күңел» радиосы алып баручысы Алинә Вәлиевага (Хисмәтуллинага), Яр Чаллы татар дәүләт театры актеры, Татарстанның атказанган артисты Илфат Мансур улы Әскәровка, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Фәннүр Сафин исемендәге әдәби премия лауреаты, балалар һәм зурлар өчен дистәләгән китап авторы Земфира Нәсыйх кызы Исламовага, «Болгар» җыр һәм бию ансамбле солисты Хаматшин Нияз Юзик улына һәм гимназия укытучыларына йөкләнгән иде. Алар бу эшне бик зур җаваплылык белән, җиңелчә дулкынлану хисләрен яшермичә, эшнең мөһимлеген тоеп башкарып чыктылар.

Иң өлкән яшьтәге акциядә катнашучы – Закиров Фоат Вафин улы – ул көнне гимназиягә, түбәтәйләрен киеп килгән иде. Шәһәрдә агачтан уеп сыннар ясаучы оста буларак танылган Фоат абыйның, үз туган теленә хөрмәтен күрсәтеп, кулына каләм алуы бик күпләрне илһамландырды.

Диктант өчен Ибраһим Газиның «Сыерчыклар» тексты сайланган иде. «“Сугыш афәте башка кабатланмасын иде”, – дигән юлларны язганда, уйга калдым: пандемия шартларында тормышның мәгънәсе тагын да арта төште, мөмкинлектән файдаланып, халкымның үз телен яратып, шушындый акция кысаларында фикердәшләрен туплавы халкымның киләчәктә дә яшәвенә ышанычны арттыра», – диде диктант язуда катнашкан гимназия директоры Гарифуллин Айдар Хәкимҗан улы.

Әлеге чарада катнашучылар киләсе елда да акция уздырылынсын дигән теләкләрен белдерделәр.

**Алия НУРИСЛАМОВА,**
*М.Вахитов исемендәге 2 нче гимназия укучысы*



# Музыка ярлары

Ул, гимназия капкасыннан кызларының мәктәп букчасын тотып кергәндә, юлында очраган һәркем белән җылы итеп исәнләшә. Аны гимназия эчендә укучыларның кызыксыну катыш хөрмәт тулы карашлары озатып кала. Аның эшләгәнен беркем дә сизми, ләкин беркөнне сәхнәгә чыгып баскан төркеме берсеннән-берсе матур җырлары белән тамашачыларны шаккаттыра. Ул кем дигән сорауны, хәтта биреп тору да урынсыздыр?! Чөнки ул гимназия укучыларының кумирына әйләнгән «Ике яр» рок-төркеме җитәкчесе Марат Минсабир улы Вәлиев.

Вакыйгалар чылбырын кайдан башларга икән? Мөгаен, Маратның үзе белем алган гимназиясеннәндер. Аның тырышлыгы, кешелеклелеге, энтузиазмы, иҗадилыгы гаилә һәм мәктәп тәрбиясенә тоташа. Маратның үсмер чагы туры килгән туксанынчы еллар ахыры рухи күтәренкелек кичергән чор буларак истә: татарча узучы КВНнар, әдәби кичәләр, иҗадилык белән янып торган гайрәтле, тирән белемле укытучылар һәм һәр яңалыкка ашкынып торучы укучылар, балаларының, үз телләрен белеп, чын татар зыялылары булып үсүләрен теләүче ата-аналар белән кайнап торган татар тормышы. Шушы вакыт шаукымы Маратның характерында зыялылыкның нәфис җепләрен чорнап калдырыргандыр, мөгаен.

Кеше үзе укыган белем йортына рәхмәтле булса, яңадан аңа әйләнеп кайта, монда аның кем булып әйләнеп кайтуы әһәмиятле түгел: ул, әти-әни буларак, үз баласын җитәкләп килергә мөмкин; ул, тәрбияче яисә мөгаллим булып, мәктәбенә кайтырга мөмкин, хәтта кунак булып кайта ала. Марат Минсабирович гимназиягә җитәкче – музыкант булып кайтты.

Гимназия, татар телендә белем бирүче уку йортлары арасында узган бәйгедә катнашып грант откач, яңа музыка уен кораллары сатып ала. 2019 нчы уку елында гап-гади укучылардан рок-төркем оеша. Соло-гитарада Кашапов Илвир, ритм-гитарада Батршин Ренат, бас-гитарада Егоров Алмаз, барабанда Вәлиева Ләйлә, синтезаторда Гафурова Адилә, бэк-вокалда Вәлиева Мәликә, вокалда чыгыш ясаучы Хабирова Линара. Әлеге укучылар арасында музыка мәктәбендә белем алганнарның да, үзлектән уйнарга өйрәнгәннәрнең булуы, аларның бер коллектив булып эшләп китүенә һич комачаулык итми, чөнки алар Марат абыйларына ышаналар.

Коллектив, кар астыннан килеп чыккан умырзая кебек, беркөнне гимназия сәхнәсен «Дим буйлары» татар халык җыры белән күмә. Сәләтле яшьләр төркеме тиз арада республикада таныла. «Мин татарча сөйләшәм» акциясенең яшь башкаручылар бәйгесендә катнашкан төркемне «Арт-Биләр» форумына чакыралар. Танылу шул вакыйгадан һәм, әлбәттә, Интернет челтәрендә урнаштырылган видео-язмалардан башлана. «Бика-фест» фестивалендә гран-при яулаган төркемнең заманча татар мәдәнияте фестивале «TatCultFest 2020»гә чакырылуы бу коллективның абруен күрсәтә. Татар халык җырларына заман сулышын өргән әлеге торкем репертуарында искиткеч матур яңгырашлы җырлар белән төркемнең үзе иҗат иткәннәре дә яңгырый.

Ничектер рок-төркем турында сөйләшеп киткәч, мин Марат Минсабировичтан аларның киенү стиле хакында сорадым һәм аның җавабыннан бик канәгать калдым: «Балалар үзләрен ирекле тоярлык, тыйнак, заманча киемнәр сайлыйлар, мин каршы килмим», – диде. Бу җөмләдә Марат Минсабирович башкарган зур хезмәтнең асылы чагыла: ул үзе тирәлегендә тудырган иҗадилык аша, үзеңнең мөмкинлекләреңә ышану, замана рухын тою хисен балаларга җиткерә белә. Ә бу бүгенге көн яшьләрендә культура һәм үзаң тәрбияләүнең төп нигезе.

**Энҗе Әзһәм кызы НУРИСЛАМОВА**





# 8в сыйныф укучылары иҗаты

## Көзге моң

Урманнарда алтын туйлар узды,
Күңелләргә инде сары моң.
Җилләр, җәйне эзләп, көз түрендә
Сагыш көен суза камышның.

**Алия НУРИСЛАМОВА**

## Көзге кәеф

Көз патша җиһанда,
Саргайды урман да
Шыбыр-шыбыр яңгыр коя.
Җәйге җылы, син кайда?

**Азалия ӘМИНОВА**

## Көз

Гаҗәеп бер матур көне көзнең,
Байлык, муллык тирә-ягымда.
Урманының алтын төсе белән
Көзләр тансык туган ягымда.
Басу бизәп, алтын иген үскән,
Арыш, бодай тулган келәткә,
Һәркем белә: көзнең бар кыйммәте
Хуш ис бөркеп торган икмәктә.

**Айсылу ИШАЛИНА**

## Көзге урман

Урман сукмагыннан атлап керәм
Табигатькә карыйм сокланып,
Шыбырдашып яфрак коелуын
Күзәтәмен читтән таң калып.

**Азалия ВАЛИУЛЛИНА**

## Ямьле җәйләр узды

Ямьле җәйләр узды,
Алар бик кадерле булды,
Саф һаваны иснәп туймадык,
Маскалардан ардык,
Яшәү ямен тойдык,
Дуслар белән тормыш кадерле.

**Динара ГОСМАНОВА**

## Көз

Сары-кызгылт төс иyртеп,
Сентябрь җитте.
Җәйнең чуар матурлыгы
Үтеп тә китте.

**Данис ДӘМИНОВ**

Минем гимназиям **Баш мөхәррир** Алия НУРИСЛАМОВА • **Редакция әгъзалары:** Азалия ӘМИНОВА • Адилә ХАНОВА • Мәрьям РИЗАТДИНОВА • Әминә ШАКИРОВА • Данис ДАМИНОВ • Ләйсән КӘРИМОВА • Камилла ЮСУПОВА • Зәринә СӘХӘБЕТДИНОВА • **Редактор-координатор:** Э. Ф. НУРИСЛАМОВА